**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге составына керүче Шалты торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР (РЕШЕНИЕ)**

17 декабрь 2021 ел № 1
14.00 сәг.
Шалты авылы, авыл мәдәният Йорты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законы нигезендә 2021 елның 17 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының «2021 елда үзара салым кертүгә Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасында укучылардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрүгә килешәсезме:

- Зиратны төзекләндерү һәм карап тоту – 61000 сум
- Юлларны ремонтлау һәм карап тоту (кардан һәм чүп үләннәреннән чистарту) – 20000 сум

«ӘЙЕ» «ЮК».

Мәсьәләсе буенча үткәрелгән җыен беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 333 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 216 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

җыенда катнашкан 209 кеше “ӘЙЕ" позициясе өчен тавыш бирде;

җыенда катнашкан 7 кеше "ЮК" позициясе өчен тавыш бирде

халык җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирүдән тыелдылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге составына керүче Шалты авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. "2022 елда Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.:

- Зиратны төзекләндерү һәм карап тоту-61 000 сум

- Юлларны ремонтлау һәм карап тоту (кар һәм чүп үләннәреннән чистарту) - 20 000 сум

3. Әлеге карарны Шалты авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендә рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://bavly.tatarstan.ru (“авыл җирлекләре” бүлегенең “Шалты авыл җирлеге” бүлекчәсе).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:

Шалты авыл җирлеге Башлыгы З.Х. Фаткуллин